Шәһәр күләмендә Татар халкы һәм Татарстан тарихы фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың шәһәр этабы биремнәре
2024-2025 нче уку елы
8 сыйныф

Эшне башкару вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 94

Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз.

1. Ханзадәләр дип кемнәрне атаганнар? (1 б.)
А. Патша уллары, хаким династия әгъзалары
Б. Татар ханлыкларында салым түләүче катлау
В. Татар ханлыкларында ясак һәм салым җыючылар
Г. Хан вәкилләре
Җавап: _____

2. Кайсы вакыйга XIII гасырга карамый? (1 б.)
А. Монгол гаскәрләренең Идел Болгарын яулап алуы.
Б. Мәнгү Тимернең идарә итүе, Җүчи Олысының мөстәкыйль дәүләткә әверелүе.
В. Алтын Урда белән Үзбәк ханның идарә итә башлавы.
Г. Алтын Урдада Бәркә ханның идарә итүе .
Җавап: _____

3. Үтәмешгәрәй исеменнән Сөембикәнең идарә итү вакытын күрсәтегез. (1 б.)
А. 1546-1550 еллар
Б. 1549-1551 еллар
В. 1548 ел
Җавап: _____

4. Алтын Урданың беренче башкаласы ничек аталган? (1 б.)
А. Кафа
Б. Болгар
В. Солхат
Г. Сарай
Җавап: _____

5. Казанда татар бистәләренең шәһәр ратушасы кайчан барлыкка килгән? (1 б.)
А. 1782 ел
Б. 1750 ел
В. 1800 ел
Җавап: _____

6. Күрсәтелгән еллар Казанда булган нинди вакыйгалар белән бәйле? (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары 10 б.).
А. 1708 ел_____
Б. 1718 ел_____
В. 1774 ел_____
Г. 1799 ел_____
Д. 1804 ел_____

7. Вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. (Тулы дөрес җавап өчен 5 б.).

А. Казан епархиясе төзелү.	
Б. Идел Болгарында рәсми төстә ислам динен кабул итү.	
В. Казан губернасы оешу.	
Г. Төрки каганлык барлыкка килү.	
Д. Казан университеты ачылу.	

8. Түбәндәге рәтләр нинди принцип буенча оешкан? (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары 8 б.).

А. Кол Шәриф, Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Котб, Г.Утыз Имәни.
Җавап: _____
Б. Туктамыш, Үзбәк, Олуг Мөхәммәд, Мәнгү Тимер, Бирдебәк.
Җавап: _____
В. Казан өязе, Лаеш өязе, Мамадыш өязе, Спасс өязе, Тәтеш өязе, Чистай өязе.
Җавап: _____
Г. Казан ханлыгы, Ногай Урдасы, Әстерхан ханлыгы, Себер ханлыгы, Кырым ханлыгы.
Җавап: _____

9. Түбәндә кайсы хөкемдарлар турында сүз барганын дөрес билгеләгез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары – 14 б.)

А. Монгол империясенә нигез салучы.
Җавап: _____
Б. Җүчи Олысы ханы. Исламны Алтын Урданың рәсми дине итүче.
Җавап: _____
В. Төрки каһанлыкка нигез салучы.
Җавап: _____
Г. Чыңгызханның оныгы, Көнбатышка яу чабу белән идарә иткән җиһангир. Җүчи Олысына нигез салучы.
Җавап: _____
Д. Европадагы Һуннар дәүләте хөкемдары.
Җавап: _____
Е. Болгар хөкемдары. Идел Болгарында ислам динен кабул итү турында Багдад хәлифәлеге белән сөйләшүләр алып баручы.
Җавап: _____
Ж. Нугай бәге Йосыф кызы, улы Үтәмешгәрәй балигъ булмаган вакытта, Казан ханлыгы хөкемдары.
Җавап: _____

10. Тарихи шәхесләрне аларның эшчәнлек төрләре белән туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары 10 б.).

Шәхес	Эшчәнлек төрләре
1) Г. Утыз Имәни	А) Педагог, тәрҗемәче, I Казан ирләр гимназиясендә татар теле укытучысы.
2) Исхак Хәлфин	Б) Татар шагыйре, татар һәм гарәп телләрендә язылган 100дән артык әсәр авторы.
3) Гавриил Державин	В) Тарихчы, “Тәварихе Болгария” хезмәте авторы.
4) Хисаметдин Мөслими	Г) Рус шагыйре, Казан губернасы Сокуры авылында туа.
5) Петр Рычков	Д) Географ, тарихчы, төбәкне өйрәнүче. Урта Идел буе тарихы буенча хезмәтләр авторы.

Җавап:

1	2	3	4	5

11. Даталарны һәм вакыйгаларны туры китерегез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б., иң югары 8 б.).

Дата	**Вакыйга**
1) 1714 ел	А) Казан адмиралтействосы ачылу
2) 1718 ел	Б) Казанда постау (сукно) мануфактурасы оешу
3) 1778 ел	В) Казан татар бистәләренең үзидарә органы Татар ратушасы оешу
4) 1781 ел	Г) Беренче татар әлифбасы нәшер ителү (авторы – С.Хәлфин)

Җавап:

1	2	3	4

12. Түбәндә китерелгән тасвирламалар буенча тарихи төшенчәләрне билгеләгез. (Һәрбер дөрес җавап өчен 2 б.; иң югары 10 б.).

А. Урта гасырда – XVIII-XV йөзләрдә татар ханнарының салым җыючы вәкиле.
Җавап: _____.
Б. Илнең бер төбәгендә чиркәү белән идарә итү оешмасы.
Җавап: _____.
В. Алтын Урдада һәм Казан ханлыгында административ-территориаль бүленеш.
Җавап: _____.
Г. Дәүләт файдасына икмәк, бал, тире яки акча белән түләнә торган салым.
Җавап: _____.
Д. Даими рәвештә бер үк урында һәм бер үк вакытта үткәрелә торган зур сәүдә.
Җавап: _____.

13. Түбәндә китерелгән өзекне укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез: (Кем исеменнән сүз барганы дөрес билгеләнгән – 3 б., тарихи вакыйгалар дөрес күрсәтелгән – 2-5 б. Иң югары – 8 б.)

Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,
Шул тынычсыз вакытта Сафагәрәем вафат.
Караштылар морзалар, Мәскәү сүзен алмыйлар,
Каршылыкны Мәскәүләр миннән диеп аңлыйлар.
Казан – Мәскәү арасында тагын бер сугыш булды...
Казандагы түрәләр солыхка кул куйганнар,
Мине Мәскәүгә озатып, тыныч тормак булганнар.

Әлеге шигъри юлларда кем исеменнән сүз бара?
Җавап: _____
Әлеге шәхес нинди тарихи вакыйгаларны күз алдында тота? Биредә аның нинди хис-кичерешләре сурәтләнә?
Җавап: _____
_____
_____

14. Фоторәсемнәрдә нинди биналар сурәтләнгән? (2 б.). Алар кайда урнашкан? (2 б.) (Иң югары 16 б.).

А.

Б.

В.

Г.

А. Җавап: _____

Б. Җавап: _____ _____

В. Җавап: _____

Г. Җавап: _____

УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!